РЕШЕНИЕ КАРАР

№1 28 октябрь 2021 ел

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлегенең Олы Шурнәк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2021 елның 28 октябрендә 14.00 хэм 16.00 сәгатьтә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 293 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 211 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашучы 192 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 19 кеше тавыш бирде; җыенда катнашкан 0 кеше «тыелды».

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлегенең Олы Шүрнәк торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, җыен нәтиҗәләре гамәлдә.

2. «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлегенең Олы Шүрнәк торак пункты чикләрендә 18 яшькә җиткән гражданнардан 500 сум күләмендә, гомуми авыру инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, югары һәм урта махсус (урта һөнәри) уку йортларының көндезге бүлекләре студентларыннан тыш, түләүләр күләме 250 сум тәшкил иткән гражданнардан үзара салым кертү белән килешеп:

- Олы Шүрнәк авылында Азин урамы буенча юл ремонты»_Мәсьәләсе буенча карар кабул итәргә.

3. Җыен нәтиҗәләрен «Новая Кама» газетасында, Олы Шүрнәк авыл җирлегенең рәсми сайтында (Олы Шүрнәк, Алабуга.рф), мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында игълан итәргә.

4. Әлеге карар Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.

Олы Шүрнәк

авыл җирлеге башлыгы Н. И. Мельников